РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРАЗМЕТЬЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ҮРӘЗМӘТ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**Үрәзмәт** **«09» декабрь 2024 ел**

**Карар №28**

**2024-2025 елларда кышкы чорда вакытлыча кар өю урыннарын билгеләү турында**

Интенсив кар яву чорында юлларны һәм урамнарны вакытында чистартуны тәэмин итү, Үрәзмәт авыл җирлегендә 2024-2025 елларның кышкы чорында территорияне җыештыруны тәртипкә салу һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә карны вакытлыча өю урыннарын билгеләү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы күрсәтмәләрен үтәү йөзеннән Үрәзмәт авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2024-2025 елларның кышкы чорында карны вакытлыча тоту өчен ачык мәйданчыклар сыйфатында түбәндәге территорияне билгеләргә:

а) 500 кв. м мәйданлы Үрәзмәт авылыннан көнчыгышта урнашкан бушлык җир кишәрлегенә кадастр номеры 16:29:130501:164 булган участокта;

б) 300 кв. м мәйданлы Бүләк авылыннан көнчыгыштарак урнашкан җир кишәрлеге кадастрлар белән янәшә урнашкан участокта

в) 300 кв.м мәйданлы Чишмә авылыннан көньяк - көнчыгышта урнашкан бушлык җир участогына кадастр номеры 16:29:130503:25 булган участокта урнашкан.

г) 300 кв.м мәйданлы Сикия авылыннан көнчыгыштарак урнашкан җир кишәрлегенә кадастр номеры 16:29:130502:4 булган участокта

2.Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә һәм хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Үрәзмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе** **Ә.Г.Закирҗанов**